## ТИЕШЛЕ БУЛМАГАН МӘГЪЛҮМАТ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫЛЫ

Законның 12 статьясында товар турында тиешенчә мәгълүмат бирмәгән өчен сатучының (агрегат хуҗасы) җаваплылыгы каралган. Мәсәлән, сатып алучыга товар турында тулы һәм дөрес мәгълүмат бирмәгән сатучы законның 18 статьясындагы 1-4 пунктларында каралган товарның җитешсезлекләре, кулланучыга мондый мәгълүмат бирмәү аркасында килеп чыккан кимчелекләре өчен җавап тота.

Кулланучыга товар яки сатучы турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат биргән, шуның нигезендә кулланучы белән сату-алу килешүе төзелгән агрегат хуҗасы тулы булмаган мәгълүмат бирү нәтиҗәсендә кулланучыга китерелгән зыян өчен җавап тота.

**Кагыйдәләрнең үтәлешен контрольдә тоту (күзәтчелек) кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт тарафыннан башкарыла.**

## КУЛЛАНУЧЫЛАР ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ БУЕНЧА БЕЛГЕЧЛӘРНЕҢ ТҮЛӘҮСЕЗ КОНСУЛЬТАЦИЯСЕН ТҮБӘНДӘГЕ ТЕЛЕФОННАР АША АЛА АЛАСЫЗ:

Татарстан Республикасы Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен һәм кулланучылар хокукларын яклауны тәэмин итү буенча дәүләт инспекциясе

**www.gosalcogol.tatarstan.ru**
**www.tatzpp.ru**

| Территориаль органы | Телефон |
|---|---|
| Әлмәт территориаль органы | (8553) 33-67-02 |
| Арча территориаль органы | (84366) 3-28-93 |
| Яшел Үзән территориаль органы | (84371) 4-58-78 |
| Казан территориаль органы | (843) 277-94-96 |
| Яр Чаллы территориаль органы | (8552) 71-43-03 |
| Түбән Кама территориаль органы | (8555) 36-63-76 |
| Чистай территориаль органы | (84342) 5-49-85 |

**Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең «кайнар линия» телефоны:**

**(843) 236-94-11**

«ВКонтакте» да онлайн-консультация»:
**www.vk.com/zpprpnrt**

«Кулланучылар хокукларын яклау.
Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор»:
**www.16.rospotrebnadzor.ru**

**«Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» ССФБУның консультация үзәге:**

**(843) 221-90-16** **www.fbuz16.ru**

**Игътибар! Сез кулланучылар хокукларын бозу турында гаризаны Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсенә тапшыра яки Татарстан Республикасының күп функцияле үзәкләре аша skype буенча кулланучылар хокукларын яклау мәсьәләләре буенча консультация ала аласыз.**

6+

© ООО «ФОЛИАНТ», 2021 г.
Тираж 7000 экз. Заказ № 31/38
Отпечатано ООО «ФОЛИАНТ». 420111 г. Казань, ул. Профсоюзная, 17в
e-mail: foliantkazan@mail.ru

# ТЕКСТИЛЬ, ТРИКОТАЖ, ТЕГҮ ҺӘМ МЕХ ТОВАРЛАРЫ, АЯК КИЕМНӘРЕН САТУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*кулланучыга белешмәлек*

**КУЛЛАНУЧЫЛАР ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ**

**Татарстан Республикасында 2014-2025 елларда кулланучылар хокукларын яклау комплекслы системасын үстерү подпрограммасын үтәү кысаларында, Татарстан дәүләт алкоголь инспекциясенең заказы буенча әзерләнде**

*на татарском языке*

**Текстиль, трикотаж, тегү һәм мех товарлары, аяк киеме сатканда кулланучы һәм сатучы арасындагы хокукый мөнәсәбәтләр «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 07.02.1992 елның 2300-1 номерлы РФ Законы (алга таба – Закон) һәм «Ваклап сату шартнамәсе буенча товарларны сату кагыйдәләрен, кулланучыга шул ук төп куллану үзенчәлекләренә ия булган товарны ремонтлау яки алыштыру чорында, шул ук төп куллану үзенчәлекләренә ия булган товарны ваклап сату-алу шартнамәсе буенча товарларны сату кагыйдәләрен раслау, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында турында»гы 2020 елның 31 декабрендәге 2463 номерлы РФ Хөкүмәте карары (алга таба – Кагыйдәләр) нигезендә җайга салына.**

**Күрсәтелгән норматив актлар Сезгә товарны дөрес сайларга, ә кирәк булганда, законлы хокукларыгызны һәм мәнфәгатьләрегезне якларга мөмкинлек бирәчәк.**

## ТОВАР ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТ

Законның 10 статьясында сатучының кулланучыга товарлар турында кирәкле һәм дөрес мәгълүматны үз вакытында бирү бурычы каралган.

Товар турында мәгълүмат (техник җайга салу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән яисә товарның туры килү-килмәвен мәҗбүри раслауны тәэмин итүче регламент атамасы; товарларның төп куллану үзенчәлекләре турында мәгълүмат; сумнарда бәясе; гарантия срогы, әгәр ул билгеләнгән булса; товарларны нәтиҗәле һәм куркынычсыз куллану кагыйдәләре һәм шартлары; товарның хезмәт итү вакыты яки яраклылык вакыты; җитештерүче турында мәгълүмат һ. б.) кулланучыларга товарларда, этикеткаларда, маркировкада яисә товарларның аерым төрләре өчен кабул ителгән башка төрләрендә тәкъдим ителә торган документларда җиткерелә.

## ВАКЛАП САТУ-АЛУ КИЛЕШҮЕ БУЕНЧА САТУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Кагыйдәләренең 62 һәм 63 пунктлары нигезендә, тукыма, кием-салым, мех товарлары һәм аяк киеме кулланучыга (аның таләбе буенча) куллану төрелмәсе өчен өстәмә түләү алмыйча гына, төрелгән рәвештә тапшырыла.

Әгәр касса чегында, текстиль, трикотаж, тегү, мех товарларына һәм аяк киемнәренә, электрон яки мондый товар өчен башка төрле түләүне раслаучы документта товарның атамасы, артикул һәм (яки) модель, сорты (булганда) турында мәгълүмат юк икән, товар белән бергә кулланучыга, аның таләбе буенча, товар чегы тапшырыла, анда әлеге мәгълүматлар, сатучының исеме, сату датасы һәм товарның бәясе күрсәтелә һәм товарны турыдан-туры сатучы зат тарафыннан имзалана.

Хайваннар дөньясы объектларыннан әзерләнгән товарларны (мех һәм тире, галантерия, декоратив эшләнмәләр, аяк киемнәре, туклану продуктлары) сату Кагыйдәләренең 72 пункты нигезендә, Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайван төрләрен кулланып әзерләнгән товарларны сату, хайваннар дөньясының бу объектлары әйләнә-тирә табигатьне яклау өлкәсендә башкарма хакимиятенең федераль органы тарафыннан бирелгән рөхсәт (лицензия) нигезендә табылганлыгы турындагы документ булганда гамәлгә ашырыла.

Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан эшләнгән, юкка чыгу куркынычы астында булган кыргый фауна һәм флора төрләре белән Халыкара сәүдә турында конвенция гамәленә кергән товарлар экспортерның компетентлы органы, ә күрсәтелгән **конвенцияне** бозу нәтиҗәсендә конфискацияләнгән товарлар вәкаләтле орган рөхсәте нигезендә сатыла.

Мондый товарларны сатканда сатучы кулланучыга, аның таләбе буенча, тиешле рөхсәт барлыгын раслаучы документлар турында мәгълүматларны бирергә тиеш.